**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**12 ноябрь 2018 ел** **№ 161**

**2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына Кама Тамагы муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш фаразы турында**

Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы М. Х. Хабибуллованың “Кама Тамагы муниципаль районының 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына социаль-икътисади үсеш фаразы турында”гы чыгышын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына районның социаль-икътисадый үсешен фаразлауның төп күрсәткечләрен расларга (1 нче кушымта).

2. Муниципаль район башкарма комитетына, сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләмнәрен арттыруны тәэмин итүгә, халыкның тормыш-көнкүреше шартларын яхшыртуга көч куюга юнәлтеп, муниципаль районның комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итәргә.

3. Җирле үзидарә органнарына, милек рәвешләре предприятиеләренә 2019 елга һәм 2020, 2021 еллар план чорына социаль-икътисадый үсешнең фараз күрсәткечләрен, 1 номерлы кушымта нигезендә, финанс-җитештерү эшчәнлегендә нигез итеп алырга тәкъдим итәргә

4.Әлеге Карарны “Волжские зори”, “Идел таннары” газеталарында бастырып чыгарырга һәм Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы, Кама Тамагы муниципаль районы Советы рәисе** **П.Н. Лоханов**